КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 октябрь г.Казань № 946

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен бүләк түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1258 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен бүләк түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1258 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «субсидияләр» сүзен «башка бюджетара трансфертлар» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «субсидияләр» сүзен «башка бюджетара трансфертлар» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль

физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен бүләк түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм аңа кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр).

2. Әлеге карарның гамәле 2020 елга (2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына) бюджетлардан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 29 декабрь, 1258 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 22 октябрь, 946 нчы
карары редакциясендә)

Тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен бүләк түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен бүләк түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә физик культура һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен бүләк түләү өлешендә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче булып Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Субсидияләр әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Субсидия алу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен сайлап алу критерийлары булып Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында түбәндәгеләр булу тора:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел,

25 сентябрь, 853 нче карары нигезендә алдагы календарь елы өчен бөтенроссия һәм халыкара ярышларда укучылар алган югары нәтиҗәләр;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары нигезендә алдагы календарь елы өчен спорт резервын бөтенроссия һәм халыкара ярышларда әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларының спортчы инструкторлары һәм спортчылары тарафыннан алынган югары нәтиҗәләр.

6. Субсидияләр түбәндәге шартларда бирелә:

спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен үз эченә алган спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең норматив хокукый акты белән расланган нигезләмә булу;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу, аларны финанслашуга бирелә торган субсидия күләменең кимендә 50 проценты күләмендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирелә;

әлеге Тәртипнең 11 пункты нигезендә субсидия бирү турында Министрлык белән килешү төзү.

7. Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

8. Тиешле финанс елына (Si) Татарстан Республикасы i муниципаль берәмлегенә башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = \sum^n{}_j = 1\ ((O_v \times Ч_{tpj}) + (B_{vrr} \times Ч_{cpj})) \times (100 + C_j) \times 12\ ,$$

монда,

$O_v$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә нигезендә исәпләнгән яулаган урыны буенча югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j муниципаль физкультура спорт оешмасында физик культура һәм спорт өлкәсендә программаларны гамәлгә ашыручы тренерлар окладлары;

$Ч_{tpl}$ – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының тренерларның фактик саны турында i муниципаль берәмлегендә соңгы ике төгәлләнгән финанс елында алынган мәгълүматлары нигезендә планлаштырыла торган j муниципаль физкультура спорт оешмасында югары квалификацияле спортчылар әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерларның уртача еллык саны;

$B_{vrr}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә нигезендә исәпләнгән ярышларда алган урын буенча югары эш нәтиҗәләре өчен спортчы-инструкторларга һәм рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгыш саган һәм ирешкән нәтиҗәләре өчен спортчыларга резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j-муниципаль физкультура спорт оешмасында түләүләр;

$Ч_{cpj}$ – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының спортчы-инструкторлар һәм спортчыларның фактик саны турында i муниципаль берәмлегендә соңгы ике төгәлләнгән финанс елында алынган мәгълүматлары нигезендә планлаштырыла торган j муниципаль физкультура спорт оешмасында ярышларда урын алучы спортчы-инструкторлар һәм рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгышлары һәм югары эш нәтиҗәләре булган спортчыларның уртача еллык саны;

$C_j$ – j муниципаль физкультура спорт оешмасы хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү хисаплау чыгымнары;

n – i муниципаль берәмлектә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары саны.

9. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары Министрлыкка Татарстан Республикасы бюджетыннан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчыларга һәм инструкторларга акчалата түләү өчен муниципаль берәмлек бюджетына субсидия алу өчен әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча гариза (алга таба – гариза) һәм ярышлар беркетмәсенең күчермәсен тапшыра.

10. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә тиешле календарь аена ($S_{im}$) финанслауның чик күләмнәрен җиткерү өчен башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_{im} = \sum^{n}{}_{j} = 1 \left(\left(O_v \times Ч_{tfj}\right) + \left(B_{vrr} \times Ч_{cj}\right) + C_j\right),$$

монда:

$O_v$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә нигезендә исәпләнгән яулаган урыны буенча югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j муниципаль физкультура спорт оешмасында физик культура һәм спорт өлкәсендә программаларны гамәлгә ашыручы тренерлар окладлары;

$Ч_{тfj}$ – спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j муниципаль физкультура спорт оешмасында югары квалификацияле спортчылар әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерларның фактик саны, хисап аена;

$B_{vrr}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә нигезендә исәпләнгән ярышларда алган урын буенча югары эш нәтиҗәләре өчен спортчы-инструкторларга һәм рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгыш саган һәм ирешкән нәтиҗәләре өчен спортчыларга резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j-муниципаль физкультура спорт оешмасында түләүләр;

$Ч_{cj}$ – спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j муниципаль физкультура спорт оешмасында ярышларда урын алучы спортчы-инструкторлар һәм рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгышлары һәм югары эш нәтиҗәләре булган спортчыларның фактик саны, хисап аена;

$C_j$ – j муниципаль физкультура спорт оешмасы хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү хисаплау чыгымнары;

n – i муниципаль берәмлектә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары саны.

11. Субсидия Министрлык һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге арасында тиешле финанс елының 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча төзелә торган субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә, анда түбәндәгеләр күздә тотыла:

субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

бирелә торган субсидиянең күләме;

субсидияләрне күчерү сроклары;

субсидия куллануның нәтиҗәлелегә күрсәткечләре;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең субсидияне максатчан файдалануын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру һәм субсидия куллануның нәтиҗәлелегә күрсәткечләрен үтәү турында алучы тарафынннан хисап бирү тәртибе, формасы һәм сроклары;

әлеге Тәртип белән билгеләнгән шартлар бозылган очракта килешүне өзү тәртибе;

якларның җаваплылыгы.

12. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче, югары квалификацияле спортчылар әзерләүгә гамәлгә ашыручы тренерлар, шулай ук ярышларда алынган нәтиҗәләре булган спортчы-инструкторлар һәм спортчылар реестрын алып бара һәм ай саен, агымдагы айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, реестрны һәм Министрлыкка субсидия бирүгә гариза тапшыралар.

13. Министрлык спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче, югары квалификацияле спортчылар әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерлар, шулай ук ярышларда алынган нәтиҗәләре булган спортчы-инструкторлар һәм спортчыларның җыелма реестрын алып бара һәм ай саен, агымдагы айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына субсидия бирү өчен гариза тапшыра.

14. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторлар һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен Министрлык тарафыннан бүләкләүгә гаризалар кергәннән соң, биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка әлеге максатларга финанслауның чик күләмнәрен җиткерүгә чыгым расписаниясен җибәрә.

15. Министрлык әлеге максатларга финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын исәпкә алу өчен Россия Банкының исәп-хисап челтәре бүлекчәләрендә ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең исәп-хисап счетына субсидия күчерә.

16. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча килешүдә каралган форма һәм тәртибе нигезендә Министрлыкка финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары чыгымнары һәм субсидия куллану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисап тапшыра.

17. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Министрлыкның башка бюджетара трансфертлар алуга гаризасы кергәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге максатларга финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерүгә чыгым расписаниесен министрлыкка җибәрә.

18. Министрлык күрсәтелгән максатларга финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча Россия Банкының исәп-хисап челтәре бүлекчәләрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын исәпкә алу өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең исәп-хисап счетына башка бюджетара трансфертларны күчерә.

19. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары хисаплылыктан соң килә торган айның 15 числосыннан да соңга калмыйча финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларының чыгымнары һәм килешүдә каралган форма һәм тәртип нигезендә бүтән бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында Министрлыкка хисап бирәләр.

20. Министрлык ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 20 числосыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Министрлыкка финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары чыгымнары һәм субсидия куллану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча хисап тапшыра.

21. Әгәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге әлеге Тәртипнең 13 пунктында каралган күрсәткечкә ирешмәсә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (кире кайтару) бирү елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар күләме әлеге Тәртипнең 13 пунктында каралган күрсәткечкә ирешелмәсә, формула буенча билгеләнә:

$$V_{возврата} = V_{мбт} \times k \times 0{,}1 ,$$

монда:

$V_{мбт}$ – финанс хисап елында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләме;

k – башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

22. Хисап финанс елында ($V_{мбт}$) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләмендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар күләмен исәпләгәндә башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына кадәр файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган күләме исәпкә алынмый.

23. Башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты (k) формула буенча билгеләнә:

$$k = 1 - \frac{T}{S} ,$$

монда:

T – башка бюджетара трансфертны куллану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең ел ахырына фактта ирешелгән күрсәткече;

S – килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең plандагы әһәмияте.

24. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын, шул исәптән Татарстан Республикасы муни-

ципаль берәмлеге тарафыннан әлеге Тәртипнең 23 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акчаларны кире кайтармау очрагында, аңа Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

25. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган субсидияләр агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияләрнең файдаланмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә алынырга тиеш.

Хисап финанс елында кулланылмый торган субсидияләргә ихтыяҗ булу турында Министрлык карары нигезендә күрсәтелгән субсидия калдыгыннан артмаган күләмдә акчалар әлеге субсидияне бирү максатларына туры килә торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен агымдагы финанс елында аңа элек бирелгән муниципаль берәмлек бюджеты керемәнә кире кайтарылырга мөмкин.

26. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияләрне максатсыз файдалану өчен законнар нигезендә җавап тота.

27. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тоту закон нигезендә Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен бүләк түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

______________________ муниципаль берәмлегенә тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен тренер-инструкторларга һәм спортчыларга бүләк түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алуга гариза

| Т/с | БЯСМ исеме | Тренер-укытучының Ф.И.Ә.и. (булганда) | Спорт төре, Бөтенроссия спорт төрләре реестры нигезендә спорт төре дисциплинасының тулы исеме | Бөтенроссия спорт төрләре реестры нигезендә спорт дисциплинасының номеры-коды | Спорт төрләре буенча төбәкара һәм Бөтенроссия спорт ярышлары турындагы нигезләмә нигезендә дисциплинаны тәкъдим итүче спортчылар саны, кеше | Укучының Ф.И.Ә.и. (булганда) | Яулаган урын | Ярышлар дәрәҗәсе | База оклады | 1 шөгыльләнүчегә % | Сумма, сум | Тренерлар саны, кеше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | |